ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

_____27.10.2021_____ Казан шәһәре № ___96_____

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе боерыкларының үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында,

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең түбәндәге боерыкларын гамәлдән чыккан дип танырга:

«Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 17 октябрендәге 112 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның 17 октябрендәге 112 номерлы боерыгы белән расланган Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 10 гыйнварындагы 2 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның 17 октябрендәге 112 номерлы боерыгы белән расланган Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм

күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 29 июлендәге 78 номерлы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2019 елның 17 октябрендәге 112 номерлы боерыгы белән расланган Төзүче оешмага төзүче оешманың һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы федераль законның 3 статьясының $1^1$ һәм 2 өлешләрендә, $3^2$, 20 һәм 21 статьяларында билгеләнгән таләпләргә җавап бирүе турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 21 июлендәге 62 номерлы.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Хокукый эш һәм өлешле төзелешне тикшерүдә тоту идарәсенең юридик бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең җыелма анализ һәм мәгълүмат технологияләре бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче В.А. Кудряшов